КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 2 декабрь г.Казань № 1084

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында

Татарстан Республикасының Тәтеш муниципаль районында «Буа – Тәтеш» – Зеленовка төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының 49 статьясы, VII1 бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт идарәсе) Татарстан Республикасының Тәтеш муниципаль районында «Буа – Тәтеш» – Зеленовка төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын төзү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен «Ярдәм» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – алына торган кишәрлек милекчесе) милкендәге Татарстан Республикасы, Тәтеш муниципаль районы, Нармонка авыл җирлеге адресы буенча урнашкан авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясендәге 12 156 771 кв.метр мәйданлы, 16:38:000000:6 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән барлыкка килә торган 28 409 кв.метр мәйданлы җир кишәрлеген (алга таба – алына торган җир кишәрлеге) алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Кушымтада күрсәтелгән, җир кишәрлегендә урнашкан капиталь төзелеш объектлары алынмый дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районындагы Нармонка авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка белдерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен алына торган җир кишәрлеге милекчесенә, «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен түләү күләме билгеләнгәннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында килешү (алга таба – килешү) әзерләүне һәм аны алына торган җир кишәрлеге милекчесенә җибәрүне;

килешү төзүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен акча түләүне;

алына торган җир кишәрлегенә Татарстан Республикасы милке хокукын дәүләт теркәвенә алуны;

алына торган җир кишәрлеге милекчесе тарафыннан имза куелган килешү законнар белән билгеләнгән срокта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъва бирүне.

4. Татарстанның юл-транспорт идарәсенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы чикләрендә урнашкан «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районында «Буа - Тәтеш» - Зеленовка автомобиль юлын төзү» объекты буенча планировка проектын һәм ызанлау проектын раслау турында» 2019 елның 18 мартындагы 247 номерлы карары белән расланган территорияне планлаштыру проекты һәм ызанлау проекты нигезендә алына торган җир кишәрлегенә карата кадастр эшләрен башкару;

алына торган җир кишәрлеге өчен акча түләү күләмен билгеләүне.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 2 сентябрь, 712 нче карарына кушымта

Җир кишәрлегендә урнашкан күчемсез мөлкәт объектлары исемлеге

| Җир кишәрлегенең кадастр номеры | Күчемсез мөлкәт объектының кадастр номеры | Күчемсез мөлкәт объекты исеме |
|---|---|---|
| 16:38:000000:6 | 16:38:000000:959 | «Юл транспортын төзү. «Нармонка - Чинчурино» |
| | 16:38:000000:1235 | «Юл транспортын төзү. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районында «Буа – Тщтеш» – Зеленовка автомобиль юлы төзелеше |
| | 16:38:090406:352 | «Биотермик чокыр» |
| | 16:38:090406:353 | «Себер түләмәсе үләт базы» |

---